**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕТРӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XLI УТЫРЫШЫ**

**КАРАР№ 71**

Метрәй авылы 24 ноябрь 2023 ел.

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының « Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советының 16 декабрендәге2020 елның 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында" 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокурорының 2023 елнын 21 ноябрендәге 02-01-12-2023 номерлы норматив-хокукый актын кабул итү кирәклеге турындагы мәгълүматне үтәү өчен, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Советының 16 декабрендәге 2020 елның 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 35 статьяның 5 өлешенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасында бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) Татарстан Республикасы Советына юлламасы нигезләмәләре;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль район Метрәй авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы
Метрәй авыл җирлеге башлыгы И.В.Шамгунов